**ГЛАВА**
**БОЛЬШЕЕЛГИНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**РЫБНО-СЛОБОДСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422640, с. Большая Елга,
ул.Октябрьская, дом 25

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БАЛЫК БИСТӘСЕ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ**
**ОЛЫ ЕЛГА АВЫЛ**
**ЖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

422640, Олы Елга,
Октябрь урамы, 25 йорт

Тел.: (84361) 25-264, факс: (84361) 25-265, эл.адрес: Belg.Rs@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2019 елның 18 октябре Олы Елга ав. № 1

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлегенең Олы Елга һәм Саескан Тавы авылларында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге “ Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 45-ЗРТ номерлы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “ Олы Елга авыл җирлеге " муниципаль берәмлеге Уставының 22 маддәсе нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлегенең Олы Елга авыл торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын 2019 елның 30 октябрендә 13 сәгать 00 минутка билгеләргә.
2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлегенең Олы Елга авыл торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын 2019 елның 31 октябрендә 10 сәгать 00 минутка билгеләргә.
3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлегенең Саескан Тавы авыл торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының 2019 елның 31 октябрендә беренче этабын 14 сәгать 00 минутка билгеләргә

4. Халык җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлү территориаль билге буенча гамәлгә ашырылуын расларга.

5. Гражданнар җыены каравына куела торган сорауны расларга:

Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлегенең Олы Елга, Сабакай, Саескан тавы, Кама поселогы авыл торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларында йөреп укучы студентлардан һәм 1 төркем инвалидлардан гайре) 500 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

- Олы Елга, Сабакай авылларында янгын гидрантын сатып алу һәм урнаштыру;

- Олы Елга, Сабакай, Саескан Тавы авылларында су җыю скважиналарына тирән насослар сатып алу;

- авыл җирлеге торак пунктларында энергияне саклый торган лампаларны сатып алу һәм алыштыру;

-Олы Елга авылында: Яшьләр урамы, Күл урамы; Мәктәп урамы, Нариман урамы,Совет урамы, Чишмә урамы, Яңа-2, Мөхәммәтгали урамы;;

- авыл җирлеге торак пунктларында урамнарның йөрү өлешен (карны чистарту) кыш көне карап тоту;

- Олы Елга авылындагы " Бизнә» елгасы аша җәяүлеләр күперен ремонтлау.

"ЯКЛЫЙМ" "КАРШЫ" .

6.Әлеге карарны дәүләт теркәвеннән соң Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында:Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы,Олы Елга авылы, Октябрь урамы, 25 нче йорт; Казаклар авылы, Үзәк урамы, 9 нчы йорт, Саескан Тавы авылы, Үзәк урам, 16А йорт, Кама поселогы, Курорт урамы- 2, 23 йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http:// ribnaya-sloboda.tatarstan.ru.веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http:// pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында кабул ителгәннән соң 3 көн эчендә.

7. Карар басылып чыккан (халыкка белдерелгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Олы Елга авыл җирлеге башлыгы Ф.Ә.Садриев